КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 гыйнвар г.Казань № 4

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче; 2017 ел, 15 август, 581 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 953 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендәге товар базарларында көндәшлекне үстерү буенча максатларның һәм бурычларның өстенлеген тәэмин итә.»;

3.2 нче пунктның унтугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән – авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны тәэмин итү, әлеге өлкәдә норматив хокукый актларның үтәлешен тикшерүдә тоту функцияләрен гамәлгә ашырганда (03.02.02);»;

3.3 нче пунктта:

3.3.1 нче пунктчада:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләрен даими (чикләнмәгән вакытта) файдалануга, арендага, түләүсез файдалануга («Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 мартындагы ТРЗ-22 номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешнең 7 һәм 9 нчы пунктларында күздә тотылган очраклардан тыш) бирүне; урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сатып алу-сату шартнамәләрен төзүне; дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына торглар, урман утыртмаларын сатып алу-сату шартнамәләрен төзү хокукына аукционнар әзерләүне, оештыруны һәм үткәрүне; урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләренә карата сервитутлар билгеләүне тәэмин итә;»;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

җиденче абзацка «йә сервитут яки Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{37}$ статьясы белән күздә тотылган максатлар өчен билгеләнгән ачык сервитут нигезендә урманнардан файдалануны гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкаруга рөхсәтнамәләр бирә;»;

егерме бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләренә карата әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны билгеләнгән тәртиптә килештерә;»;

кырык җиденче абзацта «урман утыртмалары биләгән» сүзләрен «урманнар урнашкан» сүзләренә алыштырырга;

кырык тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урман фонды җирләрендә урман кишәрлекләрен проектлаштыруны гамәлгә ашыра;»;

$3.3.1^{1}$ нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урман фонды җирләрендә урманнарны саклауны (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын һәм урман янгыннарын сүндерүне гамәлгә ашыру, урман янгыннарын локальләштерү һәм бетерү максатларында шартлату эшләрен башкарудан һәм урман янгыннарын сүндерү максатларында явым-төшемнәрне ясалма рәвештә китереп чыгару буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш), урманнарны яклауны (урманнарны яклау районнарына бүлүдән һәм урман патологиясенә дәүләт мониторингын үткәрүдән тыш), урманнарны яңадан торгызуны (урман орлыклары буенча районнарга бүлүдән, урман үсемлекләре орлыкларының федераль фондын формалаштырудан һәм урманнарны яңадан торгызуга дәүләт мониторингын үткәрүдән тыш), урманнар утыртуны гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин